


# Фәрит Яруллин – иң мәшһүр татар композиторы

Презентацияне Яр Чаллы шәһәренең “Мулланур Вахитов исемендәге 2нче гимназия” музыка укытучысы Шәйгәрдәнова Ләйсән Зөфәр кызы ясады.





Булачак композитор Фәрит Яруллин 1914 елның 1 гыйнварында Казанда туа.





Фәрит Яруллин атаклы музыкант Заһидулла Яруллин гаиләсендә милли көйләр мохитендә төрле музыка уен коралларының сихри авазларын ишетеп үсә. Әтисе аны нота грамотасына һәм фортепианода уйнарга өйрәтә.





1930 елда ФәритЯруллин Казан музыка техникумына укырга керә һәм кыска вакыт эчендә виолончельдә уйнарга өйрәнә, фортепианода уйнавын шомарта.



Фәрит Яруллин музыка техникумында укыган вакытта ук үзен сәләтле яшь музыкант итеп таныта: кинтеатрларда тавышсыз фильмнарга музыкаль иллюстрацияләр ясаучы әтисенә булыша, музыка техникумы һәм университет хорларына җитәкчелек итә, әледән-әле концертларда катнаша, язучылар һәм артистлар арасына, сәнгать дөньясына һаман саен ныграк үтеп керә.




1933нче елда Мәскәү консерваториясе каршында рабфак ачыла. Аның беренче студентлары арасында Фәрит Яруллин һәм аның дусты Заһид Хәбибуллин да була. Рабфакта бер ел укыганнан соң, Фәрит Яруллин консерватория каршындагы ачылган Татар опера студиясенә күчә. Анда ул күренекле профессор И.И. Литинский классында композиция буенча укый.



Фәрит Яруллин үзенең иҗатташ дуслары белән

Фәрит Яруллин рабфакта укыганда ук музыкаль әсәр язып карау теләге белән яна. Беренче җыр һәм романсларын, скрипка һәм фортепиано өчен кечкенә күләмле әсәрләрен дә шунда иҗат итә башлый. Ә опера студиясендә уку чорында яшь композитор вокаль һәм инструменталь миниатюралар да, виолончель өчен соната да, симфониясенең беренче кисәген  дә яза.




Үзенең беренче иҗат адымнарын “Кара урман аша”, “Фазлуш”, “Хафизәләм иркәм”, “Ашказар”, “Сибай Кантон” кебек татар-башкорт көйләрен эшкәртүдән башлый. Ул елларда романслар (А.С. Пушкин сүзләренә “Чегәннәр”, “Җырлама син, иркәм...” һ. б.) иҗат итә.



Композитор Фәрит Яруллин һәм балетмейстер Леонид Якобсон

Гармония һәм полифония нигезләрен ныклап үзләштерүче Фәрит Яруллин үзенең иң зур иҗат җимеше “Шүрәле” балетын язарга керешә. 1938нче елда, опера студиясендә укулар тәгәлләнү сәбәпле, Ф. Яруллин Казанга кайта һәм балетның клавирын 1941нче елда тәмамлый.




Абдулла Алиш

“Шүрәле” балетыннан өзекләрнең иң беренче тапкыр эфирга чыгуы исә 1940нче елның җәенә карый. Бу эшне оештыруда һәм башлап җибәрүдә Абдулла Алиш тырышлык күрсәтә. Ул яшь композитор Фәрит Яруллинның иҗат эшчәнлеген чагылдырган сценарий төзи, әдәби текстын да үзе яза, балеттан өзекләрне Фәрит Яруллин бу тапшыруда үзе уйный.



Фәрит Яруллин

Балет 1941нче елда Мәскәүдә үткәреләчәк татар әдәбияты һәм сәнгать декадасында күрсәтелергә тиеш була. Ләкин 1941нче елның 24 июлендә Фәрит Яруллин армиягә алына. Ульяновск пехота училищесында дүрт айлык хәрби әзерлек үткәннән соң, фронтка китә




Белоруссия.Рыленки туганнар каберлеге. Биредәге ташларның берсенә Фәрит Яруллинның исеме уелып язылган.

Фәрит Яруллин яу кырыннан кайта алмый: 1943нче елның октябрендә Белоруссиянең Дубровно шәһәре янындагы сугышларда һәлак була. Кызганычка каршы, композиторга балетын күрергә насыйп булмый. “Шүрәле” балеты 1944нче елда Казанда куела.



Фәрит Яруллинга, үлгәннән соң, 1958нче елда Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирү турында карар чыгарыла.



Фәрит Яруллинның хатыны Галина һәм кызы Наилә.




Мирсәет Яруллин (1938-2009) – татар композиторы, педагог, Фәрит Яруллинның бертуган энесе.







Рәссам, скульптор Бакый Урманчы ясаган Фә




Фәрит Яруллинның тормышына һәм иҗаты юлына багышланган китаплар




Рашат Низамиев Фәрит Яруллин турында “Ут һәм җыр” дип исемләнгән роман-хроника иҗат итте.





*Яруллиннарның нәсел башы Заһидулла, аның уллары Фәрит һәм Мирсәет*

Яруллиннарның  туган авылы булган Мамадыш районының Кече Сөн авылында Фәрит Яруллин музее эшли.




Фәрит Яруллин исемендәге Әлмәт шәһәренең музыка көллияте

Фәрит Яруллин исемен Казан шәһәренең Киров районындагы бер урамы йөртә;
Әлмәт шәһәренең музыка көллиятенә Фәрит Яруллин исеме бирелгән;
Мамадыш шәһәренең сәнгать мәктәбе Яруллиннар исемен йөртә.




Белоруссиянең Любровно шәһәре Балалар сәнгать мәктәбе Фәрит Яруллин исемен йөртә, мәктәп янына Фәрит Яруллинның һәйкәле куелган.

## Әдәбият


1. Сәйфуллин. Р.Т. Музыка дәресләре: 5-7 нче сыйныфлар: Укытучылар өчен методик кулланма / Р. Т. Сәйфуллин. – Казан: Мәгариф, 2004. – 183 б.

2. Кырык татар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 375 б.

3. Музыканты мира: Биографический словарь / Сост. М.В. Есипова, О. В. Фраёнова. – Большая российская энциклопедия, 2001. – 527  с.:ил.

Интернет – ресурслар:

1. Белоруссиядә татар композиторы Фәрит Яруллинга һәйкәл ачылды [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://tatar-inform.tatar/news/culture/03-07-2017/belorussiyad-tatar-kompozitory-f-rit-yarullinga-yk-l-achyldy-5586168, свободный – (10.04.2020).
2. Презентация на тему : «Фәрит Яруллин (1914-1943) [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://www.myshared.ru/slide/1235635/, свободный – (10.04.2020).
3. Фәрит Яруллин [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://yandex.ru/images, свободный – (10.04.2020)